СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**11 сентябрь 2020 ел** **№ 54**

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатыннан "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы Федераль закон, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2009 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы," Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 1 нче кушымта итеп бирелгән Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими рәвештә башкаручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмәне расларга.

2. 2 нче кушымта итеп бирелгән Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

4. Әлеге карарда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, ЕГИССОны куллану юлы белән алынырга мөмкин.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов

СОВЕТ НОВОКИШИТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609002944